СОВЕТ ВЕРХНЕСУБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ СУБАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«31» октябрь 2022 г. № 57

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл жирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым җыю һәм файдалану тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 56 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Югары Субаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Югары Субаш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Югары Субаш авыл җирлеге Советының 11.04.2014 ел, № 98 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге территориясендә үзара салым җыю һәм гражданнарның үзара салымы тәртибе турында нигезләмәгә кертергә (14.11.2017 №64 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр:

1.1. Нигезләмәнең 5.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Җирле референдумда кабул ителгән карарларның 18 яшькә житкән барлык гражданнар, җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш бирүдә белдерелгән мөнәсәбәтләргә карамастан, 1 нче группа инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы тол хатыннарыннан, мобилизацион гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына кала, гражданнарның үзара салым акчалары җирле референдумда кабул ителгән карарларның нәтиҗәләрен игълан иткәннән соң өч ай дәвамында түләнә, алар өчен җирлек башкарма комитетының банк реквизитларын, шулай ук түләү тәртибе турындагы мәгълүматны үз эченә алган хәбәрнамә нигезендә үзара салым суммасының 90% күләмендә ташлама билгеләнгән

2. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны районның baltasi.tatarstan.ru. рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан ителәә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Югары Субаш авыл җирлеге башлыгы А. А. Хөснетдинов